МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.12.2019 Казан ш. № 07-131

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру хакында

“Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” 28.03.2019 ел, № 233 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисапны (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Бу боерыкның үтәлешен контрольлектә тотуны министр урынбасары А.Л.Анфимовага йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының
10.12.2019 № 07-131
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе

1. Бу Боерык, "Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" 28.03.2019 ел, № 233 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, шәһәр округы, муниципаль район башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап (алга таба – Хисап) тапшыру кагыйдәләрен, срокларын һәм формасын билгели.

2. Хисап, өтердән соң икенче вакланма дистәгә кадәр төгәллек белән, сумнарда төзелеп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла.

3. Шәһәр округы, муниципаль район башкарма комитеты кәгазьдә (бер үк вакытта «БАРС Web-Своды» программа комплексында электрон рәвештәге күчермәсен булдыру нигезендә) хисап тапшыра. Шул ук вакытта кәгазьдәге һәм электрон рәвештәге хисаплар бер үк төрле булырга тиеш. Хисап, бу Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча, хисап финанс елыннан со килүче елның 1 гыйнварына төзелә һәм хисап финанс елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

3. Кәгазьдәге хисапка муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе, муниципаль районның (шәһәр округы) финанс органы җитәкчесе һәм эш башкаручы (вазифасын, элемтәгә керү өчен телефон номерын күрсәтеп) кул куя, тулы имзалар, кул кую датасы күрсәтелеп, хисап әлеге органнарның мөһере белән раслана.

Татарстан Республикасы муниципаль
берәмлекләре бюджетларына муниципаль
берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне
финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә торган
башка бюджетара трансфертлардан файдалану
турында хисапны тапшыру тәртибенә кушымта

Форма

Чыгым турында хисаплар

______________________________________________________ бюджеты

*(муниципаль район (шәһәр округы атамасы)),*

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар торган

20___ елның 1 гыйнварына

Үлчәү берәмлеге: сумнарда

| Җирлек (шәһәр округы) атамасы | Хисап елы башына средстволар калдыгы, барлыгы | шул исәптән: | Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән средстволар | Тотылган средстволар (касса чыгымы) | Узган елларның торгызылган бюджетара трансфертлар калдыклары | шул исәптән: | Хисап елы азагына средстволар калдыгы, барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ихтыяҗы расланган | | | | Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылган | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| Барлыгы: | | | | | | | |

Муниципаль район (шәһәр округы)
башкарма комитеты җитәкчесе

____________________/__________________________
(имза) (тулы имза)

М.У.

Муниципаль район (шәһәр округы) финанс органы җитәкчесе

_____________________/_________________________
(имза) ) (тулы имза))

М.У.

Эш башкаручы _______________________________________________________________________________
(вазифа) (имза) (тулы имза) (код белән телефон)